СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**«09» сентябрь 2026 ел**

**№ 21**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының “Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 60 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 24 апрелендәге 72 номерлы үзгәрешләр белән)**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча муниципаль районының “ Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының “ Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 60 номерлы карары белән расланган (2023 елның 24 апрелендәге 72 номерлы үзгәрешләр белән) Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең тулы хокуклы составындагы вәкиллекле органының беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы — Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ